**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ГЛАВА УЛЬЯНОВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**УЛЬЯНОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**

423115, Ульяновка село, Центральная ул., 44 дом
тел./факс+7(84396)
2-33-16/2-33-17
email: Ul.Cmn2@tatar.ru
423115, Ульяновка авылы, Үзәк урамы, 44 йорт

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**20 октябрь 2025 ел** **№ 04**

**«Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Иске Котыш һәм Ульяновка авыл җирлекләре территориясендә урнашкан «Иске Кади нефть ятмасының 1480 нче скважиналар куагын төзекләндерү. К-1480 дән БГ 396 га кадәр нефть промыселы үткәргечен төзү» линия объектын урнаштыруны күздә тотучы территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты документациясен раслау турында» гы мәсьәлә буенча гавами тыңлауларны билгеләү турында**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Ульяновка авыл җирлеге Уставының 19 статьясы нигезендә **КАРАР БИРӘМ:**

1. «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Иске Котыш һәм Ульяновка авыл җирлекләре территориясендә урнашкан «Иске Кади нефть ятмасының 1480 нче скважиналар куагын төзекләндерү. К-1480 дән БГ 396 га кадәр нефть промыселы үткәргечен төзү» линия объектын урнаштыруны күздә тотучы территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты документациясен раслау турында» гы мәсьәлә буенча гавами тыңлауларны 2025 елның 11 ноябренә билгеләргә.

2. Гавами тыңлаулар күрсәтелгән көнне 16.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр уздырыла дип билгеләргә, гавами тыңлаулар үткәрү урыны –Ульяновка авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе кабинеты (адресы: Татарстан Республикасы, Чирмешән муниципаль районы, Ульяновка авылы, Үзәк ур., 44 йорт).

3. Җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалануны үзгәртү мәсьәләсен исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

Шәмсетдинов С.З. - Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Ульяновка авыл җирлеге башлыгы;

Матросова М.Г. - Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Ульяновка авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - эшче төркем секретаре;

Елина В.П. - Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Ульяновка авыл җирлеге Башкарма комитетының әйдәп баручы белгече-комиссия әгъзасы.

4. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

а) Ульяновка авыл җирлегендә яшәүчеләр Проект буенча фикер алышуда әлеге карар белән билгеләнгән гавами тыңлауларда катнашу юлы белән Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 46 статьясында һәм Ульяновка авыл җирлеге уставында билгеләнгән тәртиптә катнашалар;

б) гавами тыңлауларга әзерлек барышында Ульяновка җирлегендә яшәүчеләрнең гавами тыңлауларга чыгарылган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәрен кабул итү, карау һәм исәпкә алу алып барыла;

в) Ульяновка авыл җирлегендә яшәүчеләрнең тәкъдим ителгән сорау буенча язма тәкъдимнәре («гавами тыңлауларга» тамгасы белән) 2025 елның 11 ноябренә кадәр эш көннәрендә 08.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Татарстан Республикасы, Чирмешән районы, Ульяновка авылы, Үзәк урамы, 44 йорт. Тәкъдимнәр шулай ук Ульяновка авыл җирлегендә яшәүчеләр тарафыннан почта аша күрсәтелгән адрес буенча җибәрелергә мөмкин.

г) Ульяновка авыл җирлегендә яшәүчеләрнең гавами тыңлауларга чыгарылган мәсьәләләр буенча язма тәкъдимнәрен алдан караганда эшче төркем гавами тыңлаулар барышында каралырга тиешле мәсьәләләр арасыннан түбәндәгеләрне төшереп калдыралар:

- аноним тәкъдимнәр;

- әлеге карар нигезендә гавами тыңлауларга чыгарылган мәсьәләгә кагылышлы булмаган тәкъдимнәр;

- 2025 елның 11 ноябрендә 16.00 сәгатьтән соң килгән тәкъдимнәр.

5. Ульяновка авыл җирлегендә яшәүчеләрнең гавами тыңлауларда катнашу теләге турында гаризалары (кызыксынган затның шәхесен таныклаучы документның төре, сериясе һәм номеры күрсәтелгән) 2025 елның 11 ноябренә кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә дип билгеләргә: Татарстан Республикасы, Чирмешән районы, Ульяновка авылы, Үзәк урамы, 44 йорт.

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» нда: https://pravo.tatarstan.ru һәм Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында: https://cheremshan.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районының
Ульяновка авыл җирлеге башлыгы С.З. Шәмсетдинов